| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

15.05.2024 Баулы шәһәре № 127

«2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы
Баулы шәһәр Советы карары белән расланган,
Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре»
муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»
Баулы шәһәр Советы карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы (2022 елның 14 сентябрендәге 65 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 109 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Баулы шәһәр Советы карары проектын хупларга һәм фикер алышуга чыгарырга, шул исәптән җәмәгать тыңлауларына да (1 номерлы кушымта)

2. 1 номерлы кушымта буенча карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

3. Расларга:

- “2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында” Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе һәм гражданнарның фикер алышуда катнашуы (2 номерлы кушымта);

- “2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында” Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибе (3 номерлы кушымта) (2022 елның 14 сентябрендәге 65 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 109 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән).

4. Әлеге карарны Татарстан республикасы http//pravo.tatarstan.ru. рәсми хокукый

мәгълүмат порталында һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

5. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1. Тимофеев Станислав Николаевич - эшче төркем рәисе.

2. Мөхәммәтшина Римма Марсель кызы - эшче төркем әгъзасы.

3. Садыйкова Гөлнара Зәкәри кызы - эшче төркем әгъзасы.

6. “2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы (2022 елның 14 сентябрендәге 65 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 109 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында” Баулы шәһәр Советы карары проекты буенча җәмәгать тыңлауларын 2024 елның 7 июнендә 16.00 сәгатьтә Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының киңәшмәләр залында, Татарстан Республикасы, Баулы районы, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 санлы йорт адресы буенча үткәрергә.

7. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча Баулы шәһәр Советы депутатларының һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә һәм Баулы шәһәр Советы каравына чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров

2024 елның 15 маендагы
127 номерлы
Баулы шәһәр
Советы карарына
1 номерлы кушымта

«2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Баулы шәһәр Советы карары
ПРОЕКТЫ

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль үзгәрешләр кертү турында 2023 елның 2 ноябрендәге 517-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә, (2022 елның 14 сентябрендәге 65 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 109 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

8 статья:

19 пунктны «, шулай ук су объектларын рекреацион максатларда куллану кагыйдәләре;» сүзләре белән тулыландырырга;»;

31 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

33 статьяның 26 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хокукый актларны игълан итү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яки) челтәр басмасы оештыру;»;

49 статьяның 5 пунктчасында:

7 пунктчаның уникенче абзацын «, шулай ук су объектларын рекреацион максатларда куллану кагыйдәләре;» сүзләре белән тулыландырырга

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

78 статьяда:

78 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«78 статья. «Муниципаль хокукый актларны игълан итү һәм аларның үз көченә керү тәртибе

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге оештыручы булган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми игълан ителүе булып аларның:

1) тулы текстны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Рәсми порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык ЭЛ ФС77-60244 номерлы элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан, 2013 елның 17 декабрендә бирелгән;

2) рәсми сайтта, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бүлегендә, Баулы муниципаль районы рщсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә (https://bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Гражданнарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталына керүне тәэмин итү буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә бәйләнеш пункты, Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Гоголь урамы, 21А йортында урнашкан китапханә системасы учреждениесендә эшли.

44. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында

төзелә торган килешүләр, муниципаль хокукый актлардан яки Федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлар булган аерым нигезләмәләрдән тыш, имзаланганнан соң 7 көн эчендә игълан ителә.

5. Баулы шәһәр Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр акт үзе башканы билгеләмәсә, имзаланган көннән үз көченә керә.

7. Вакытлы матбугат басмалары, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның домен исемнәрен күрсәтеп челтәр басмалары һәм аларның массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турында мәгълүмат, аларда муниципаль хокукый актлар игълан ителү (рәсми басылудан тыш), шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр исемлеге Баулы шәһәр Мэрының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән бөтен кешегә җиткерелә.».

2. Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен Уставны юстиция органына җибәрергә.

3. Уставны дәүләт теркәвеннән соң, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

Баулы шәһәр
Советы карарына
2 номерлы кушымта

“2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында”
карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу

ТӘРТИБЕ

1. «2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проектына тәкъдимнәр Баулы шәһәр Советына, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 санлы йорт адресына, язма рәвештә кертелә.

Тәкъдимнәр карар чыкканнан соң бер ай эчендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр эш көннәрендә кабул ителә.

2. Җәмәгать тыңлауларында катнашу өчен гаризалар шәхсән яки почта аша 423930, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 санлы йорт адресы буенча, конвертта, «Устав турында фике алышу» яки «Җәмәгать тыңлаулары» билгесе белән бирелә.

2024 елның 15 маендагы
127 номерлы
Баулы шәһәр
Советы карарына
3 номерлы кушымта

«2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында»
карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү

ТӘРТИБЕ

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» (алга таба - ачык тыңлаулар) карар проекты буенча тыңлаулар, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, әлеге Тәртиптә үткәрелә.

2. Ачык тыңлауларда шулай ук үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы булган, ачык тыңлаулар уздыру комиссиясенә ачык тыңлаулар уздырырга 7 көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә гариза биргән, шәһәр халкы катнаша ала.

3. Ачык тыңлауларда, ачык тыңлауларда чыгыш ясарга хокукы булмаган, барлык кызыксынган шәһәр кешесе катнаша ала.

4. Катнашучыларны ачык тыңлаулар башланыр алдыннан 1 сәгать кала теркәү башлана.

5. Ачык тыңлауларда Баулы муниципаль берәмлеге Башлыгы яки аның кушуы буенча муниципаль берәмлекнең башка вазифалы кешесе рәислек итә.

6. Җәмәгать тыңлаулары рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышу мәсьәләсенең асылы, тыңлаулар үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Протоколны рәсмиләштерү, килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен, рәислек итүче тәкъдиме буенча, ачык тыңлауларның, җитәкче һәм секретариатның ике әгъзасы составында, секретариат сайлана.

8. Төп доклад белән эшче төркем әгъзасы чыгыш ясый.

9. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар чыгыш ясау хокукы белән гариза бирү вакытына бәйле рәвештә үз тәкъдимнәрен чиратлап дәлилләү өчен чакырыла.

10. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәис рөхсәте белән чыгыш ясау вакыты озайтылырга мөмкин, әмма 3 минуттан артык түгел.

11. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга, рәислек итүче рөхсәте белән, сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар җәмәгать тыңлаулары барышына кысылырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Җәмәгать тыңлауларын үткәргәндә тәртип саклау җәмәгать тыңлауларында катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Катнашучылар ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен бозган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне аңлату, төгәлләү өчен, ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның тәкъдимнәре һәм искәртүләре язма рәвештә секретариатка бирелә һәм ачык тыңлаулар протоколына беркетелә. Ачык тыңлаулар протоколы рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм билгеләнгән тәртиптә Советның материалларында саклана.

17. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча нәтиҗә эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тыңлауларны үткәрүне һәм матди -техник яктан тәэмин итүне оештыру Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы Аппараты тарафыннан башкарыла.